РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ** ВАРЯШ-БАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**СОВЕТЫ**

*423979, РТ,Муслюмовский район, с.Варяш-Баш, ул.Кооперативная, 31а,*
Vbash.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-07-20*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВӘРӘШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XLIV УТЫРЫШЫ

## К А Р А Р № 2

Вәрәшбаш авылы 28 гыйнвар, 2019 ел

**Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитетының 2019 елга ниятләнелә торган төп чаралар планын раслау турында**

Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгы Маннапова З. М. мәгълүматын тыңлап, фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 33 нче маддәсе нигезендә Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 елга ниятләнгән төп чаралар планын расларга (1 нче кушымта).
2. Даими комиссияләргә 2019 елга Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы тарафыннан ниятләнгән төп чаралар планында каралган мәсьәләләрне вакытында әзерләүне тәэмин итәргә.
3. 2019 елга Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан ниятләнгән төп чаралар планын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарның үтәлеше өчен җаваплылыкны Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы башлыгы: З.М.Маннапова**

Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
28.01.2019 ел, 2 нче санлы
карарына 1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге Советында 2019 елга ниятләнгән ТӨП ЧАРАЛАР ПЛАНЫ**

## I. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы утырышлары

**Гыйнвар - февраль**

1. Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгының 2018 елда башкарылган эшләр турында отчеты;
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең 2018 елда бюджет үтәлеше һәм Вәрәшбаш авыл җирлегенең төгәлләштерелгән бюджетына үзгәрешләр кертү турында;
3. 2019 елга төп чаралар планын раслау турында;
4. “Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында ( 1 укылыш);
5. "Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (II укылыш);
6. Муниципаль берәмлек Советы. депутатларының сайлау округларындагы эшләре буенча мәгълүматлары

***Март – апрель***

1. 2019 елгы язгы ташу чорында биналарның, күперләрнең һәм башка корылмаларның сакланышын тәэмин итү турында ;
2. Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә хокук тәртибен ныгыту буенча даими комиссияләр һәм иҗтимагый оешмалар эше;
3. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшләре турында мәгълүматлары.

***Май –июнь***

1. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшләре турында мәгълүматы

2. Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләре үтәлеше турында;
3. 2019 елда балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәт яшәү рәвешен, мәшгульлеген оештыру турында.

***Июль-август***

1. Вәрәшбаш авыл җирлегенең 2019 елның 1 артыеллыгында бюджет үтәлеше турында;
2. Бюджет учреждениеләрен яңа ягу сезонына әзерләүнең барышы турында;
3. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшчәнлеге турында мәгълүмат.

***Сентябрь – октябрь***

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенең 2020 елга бюджет проекты турында;
2. 2019-2020 еллар ягулык чорына бюджет оешмаларының әзерлеге турында;
3. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшчәнлеге турында мәгълүматы.

***Ноябрь – декабрь***

1. Вәрәшбаш авыл җирлеге бюджетының 2019 елның 11 аенда үтәлеше турында ;
2. 2020 елга Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы билгеләгән төп чараларны раслау турында;
3. Вәрәшбаш авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында.(1 укылыш);
4. Вәрәшбаш авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында.(2 укылыш);
5. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы депутатларының сайлау округларындагы эшләре турында мәгълүматы
6. 2019 елга йомгак ясау.

## II. Оештыру чаралары

1. Югары хакимият органнары карарлары, Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы карарлары, гражданнардан кергән шикаятьләрне, мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны вакытында карап тикшерү буенча контрольне гамәлгә ашыру.
2. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советының, Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы депутатларының халык алдында отчетларын оештыру.
3. Бюджет оешмалары җитәкчеләре белән төрле мәсьәләләр буенча киңәшмәләр уздыру.
4. Даими комиссия әгъзаларын Совет утырышына төп мәсьәләләр әзерләүгә җәлеп итү.

## III. Вәрәшбаш авыл җирлеге Советы даими комиссияләре каравына куела торган мәсьәләләр

*Бюджет-финанс ,авыл хуҗалыгы һәм төзелеш мәсьәләләре буенча даими комиссия.*

1. Бюджет үтәлеше турында, 2018 елга Вәрәшбаш авыл жирлегенең төгәлләштерелгән бюджетына үзгәрешләр кертү турында.
2. Вәрәшбаш авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021и 2022 еллар план чорына бюджеты турында.

*Мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре, сәламәтлек саклау, социаль мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссия.*

1. Даими комиссиянең перспектив эш планы турында.
2. Халыкның ялын оештыру буенча мәдәни учреждениеләр (мәдәният йорты, китапханә) эше турында.
3. Мәктәп, мәдәният йортларын кышкы ягулык сезонына әзерләүнең барышы турында.
4. Мәгариф учреждениеләренең яңа уку елына әзерлеге турында.

## IV. Даими комиссияләр эшчәнлеген координацияләү.

1. Агымдагы елга эш планы төзүдә ярдәм күрсәтү.

2. Утырышларда, җыелышларда,халык җыеннарында, сайлаучылар, депутатлар тарафыннан әйтелгән тәнкыйть күрсәтмәләрнең, тәкъдимнәрнең үтәлешен контрольдә тоту.

**Вәрәшбаш авыл җирлегендә ХАЛЫК ҖЫЕННАРЫ**

| № | Көн тәртибе | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| | **1 – КВАРТАЛ** | | |
| | Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгының 2018 елда башкарылган эшләре турында отчеты. | График нигезендә | Авыл җирлеге башлыгы |
| | Авыл җирлеге территориясендә оператив хәлләр турында | гыйнвар | Авыл җирлеге башлыгы |
| | Җирлек гражданнарыннан үзара салым җыю барышы турында | февраль | Авыл җирлеге башлыгы |
| | 2019 елгы язгы ташу чорында биналарның, күперләрнең һәм башка корылмаларның сакланышын тәэмин итү турында | март | Авыл җирлеге башлыгы |
| | **2 – КВАРТАЛ** | | |
| | Шәхси хуҗалыктагы малларны көтүлекләргә чыгару | Май | Авыл җирлеге башлыгы |
| | Янгын куркынычсызлыгы турында | Май | Авыл җирлеге башлыгы |
| | Авылларны төзекләндерү һәм санитар чистарту турында. | Май | Авыл җирлеге башлыгы |
| | **3 – КВАРТАЛ** | | |
| | Халыкны эчәр су белән тәэмин итү | Август | Авыл җирлеге башлыгы |
| | Төрле мәсьәләләр | Август | Авыл җирлеге башлыгы |
| | **4 – КВАРТАЛ** | | |
| | Үзара салым акчасына башкарылган эшләр турында хисап | октябрь | Авыл җирлеге башлыгы |
| | Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясендә террорчылык актларын кисәтү һәм җәмәгать куркынычсызлыгын көчәйтү чаралары турында | декабрь | Авыл җирлеге башлыгы |

Мөслим муниципаль районы
Вәрәшбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
28.01.2019 ел, 2 нче санлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елга ниятләнгән ТӨП ЧАРАЛАР ПЛАНЫ**

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Вәрәшбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елдагы эшчәнлеге турында хисабы | гыйнвар | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2. | Башкарма комитетның 2019 елга эш планын раслау | гыйнвар | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 3. | 2019 ел өчен хисапларны әзерләү һәм тапшыру | График нигезендә | зам.руководителя исполкома |
| 4. | Авыл җирлекләре арасында узучы XXIX кышкы спартакиадада катнашу | февраль-март | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 5. | Авыл җирлекләре арасында узучы үзешчән сәнгать смотр - конкурсына әзерлек һәм катнашу | февраль-март | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 6. | Бюджет учреждениеләрендә электр энергиясе, газ куллануны контрольдә тоту | даими | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 7. | Ватанны саклаучылар көненә багышланган чаралар | 20.02-23.02 | Клуб мөдирләре |
| 8. | 8 Март Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган чаралар | 01.03-10.03 | Клуб, мәктәп директорлары |
| 9. | Үзара салым акчаларын җыю | 01.04.201га кадәр | Башкарма комитет |
| 10. | 1 Май бәйрәменә багышланган бәйрәм чаралары | 28.04-01.05 | Директора СДК |
| 11. | 1941 - 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 74 -еллыгы уңаеннан тантаналы чаралар үткәрү, сугыш ветераннарын, тыл хезмәтчәннәрен (кирәк булганда өйләренә барып) котлау | май | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 12. | Исламов И. З. крестьян-фермер хуҗалыгына һәм «Август-Муслюм» агрофирмасына язгы | май-август | Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кыр эшләрен үткәрүдә һәм урып-җыю чорында ярдәм күрсәтү | | җитәкчесе |
| 13. | Балаларның җәйге ялын һәм хезмәтен оештыру | июнь-август | Белем бирү оешмалары җитәкчеләре |
| 14. | Авыл җирлеге территорияләрен җыештыру буенча өмәләр оештыру. | май-октябрь | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 15. | Вәрәшбаш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләрен оештыру | май-октябрь | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 16. | "Сабантуй" милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | июнь | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 17. | Авыл хуҗалыгы формированияләренә терлек азыгы әзерләүдә ярдәм итү | июнь-июль | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 18. | Җир салымын һәм физик затларның милкенә салымны җыюны оештыру. Бурычлылар белән эш. | Ел дәвамында | Башкарма комитет |
| 19. | Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны, эчкечелекне кисәтү буенча профилактик эш | даими | полициянең участок вәкиле, мәктәп,клуб директорлары, ДНД |
| 20. | Җылыту сезонына әзерлек | июль-сентябрь | Оешма җитәкчеләре |
| 21. | Республика көненә багышланган бәйрәм чаралары үткәрү | 30.08 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 22. | Ындыр табакларына эшләү өчен Халыкны һәм учреждениеләр хезмәткәрләрен мобилизацияләү | Август-сентябрь | Башкарма комитет җитәкчесе, оешма җитәкчеләре |
| 23. | Белем көненә багышланган чаралар | 01.09 | Мәктәп директорлары |
| 24. | Өлкәннәр көненә багышланган чаралар үткәрү. Ялгыз, аз керемле гражданнарга бару | 1-10.10 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 25. | Әниләр көненә багышланган чара . Әниләр һәм балалар катнашында конкурс | ноябрь | Клуб, китапханә мөдирләре |
| 26. | Инвалидлар декадасын үткәрү | 1-10 декабря | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 27. | Сугыш һәм хезмәт ветераннарына һәрьяклап ярдәм күрсәтү. Пенсионерлар һәм ветераннар проблемаларын хәл итүдә катнашу | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 28. | Халык  җыеннары үткәрү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 29. | Хәйрия акцияләрендә катнашу | Уздырылган саен | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 30. | Районара узучы семинарларда, киңәшмәләрдә катнашу | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 31. | Җирлек территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү буенча эш | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 32. | Хокук бозуларны профилактикалау , торак пунктларның, асоциаль гаиләләрнең янгынга каршы торышын тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 33. | Яңа елга әзерлек. Кар сыннары конкурсы. | декабрь | Оешма җитәкчеләре |

**Вәрәшбаш авыл җирлеге**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **Маннапова З. М.**